# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге составына керүче Әлки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

10.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Исәк авыл җирлегенең Әлки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлки авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны-124 кеше.

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 113 катнашучы кертелде.

Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 86 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 86 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге составына керүче Әлки авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныргa.

2.«Исәк авыл җирлегенең Әлки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлки авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Әлки авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ З.Р.Мөхәммәтҗанова

Исәк авыл җирлеге башлыгы __________________ З.Р.Мөхәммәтҗанова